**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының**
**Лельвиж авыл җирлеге Башлыгы**
**карары**

**8 ноябрь, 2024 ел** **№ 5**

**Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлеге Лельвиж авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2024 елның 22 ноябрендә 9 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлегенең Лельвиж авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Лельвиж авылы, Мәктәп ур., 2 адресындагы авыл клубы бинасында уздырырга.

2. 2024 елның 22 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлегенең Лельвиж авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Лельвиж авылы, Мәктәп ур., 2 адресындагы авыл клубы бинасында уздырырга.

3. 2024 елның 22 ноябрендә 16 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлегенең Лельвиж авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Лельвиж авылы, Мәктәп ур., 2 адресындагы авыл клубы бинасында уздырырга.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Лельвиж авыл җирлегенең Лельвиж авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түбәндәгеләрдән тыш:
- 1 төркем инвалидлары;
- көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлар (курсантлар);
- 80 яшькә җиткән затлар һәм аннан да өлкәнрәкләр;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлар;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары;
- махсус хәрби операциядә катнашучы контракт хезмәте хәрбиләре һәм аларның гаилә әгъзалары 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

**- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау** *(урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре);*

**- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны**

**һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау**
*(материаллар сатып алу, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту буенча башка эш төрләре); (су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, (Лельвиж авылында су суырту манарасын урнаштыру өчен җир кишәрлеген рәсмиләштерү)*

*- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын* **(чишмәләрне) төзекләндерү** *(Лельвиж авылы чишмәләрен карап тоту, ремонтлау, төзекләндерү, чишмәләрне төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре, проект-смета документлары, эшләү, килешү буенча түләү)*

**- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту** *(Лельвиж авылында урам-юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, проект-смета документлары, юлларны карап тоту буенча башка эш төрләре)(юлларга вак таш салу, ремонтлау һәм төзекләндерү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, юлларны төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре);*

**- торак пункт территориясен төзекләндерү** *(Лельвиж авылы территориясен төзекләндерү, җәен печәнен чабу һәм кышын кардан арындыру, проект-смета документлары, килешү буенча эш өчен түләү, территорияне төзекләндерү буенча башка эш төрләре),*
*(спорт мәйданчыгын төзү, карап тоту, төзекләндерү, җиһазлау, инвентарь, җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, спорт мәйданчыгын төзү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);*
*(трактор тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета һәм документлар өчен түләү);*

**- һәйкәлләрне** *(Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (мемориаль корылмаларны (һәйкәлне, обелискны, мемориаль такталарны) һәм янәшәдәге территорияләрне сатып алу, урнаштыру, ремонтлау, урнаштыру, карап тоту һәм төзекләндерү, проект-смета документлары, технадзорны гамәлгә ашыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү килешү буенча, мемориаль корылмаларны сатып алу, урнаштыру, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка төр эшләр)*

**- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү** *(мотопомпа сатып алу)*

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүлү.

5. Лельвиж авыл җирлеге башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

6. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

7. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Лельвиж авыл җирлеге башлыгы: Э.Ю. Игнатьева